**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«30» март 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пункты гражданнары җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай торак пунктында 2020 елның 13 ноябрендә кабул ителгән 5 номерлы элек расланган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында халык җыенының 13.11.2020 ел, № 6 карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары һәм уку йортларында көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны югарыда күрсәтелгән карарлар белән расланган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелергә мөмкин булган эшләр исемлеген түбәндәгечә бәян итәргә:

Салдакай авылының Үзәк урамында ял итү зонасын булдыру һәм төзекләндерү;

Салдакай авылындагы К. Маркс урамы буенча күлне чистарту, күл ярларын ныгыту һәм төзекләндерү;

Салдакай авылы чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

Салдакай авылында урам утларын ясау һәм карап тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин